бует отдельного проекта и финансирования, и возможна после налаживания в здании устойчивого и благоприятного температурно-влажностного режима.

Подводим итоги. В ходе организационных усилий БФ им.Г.Р.Державина, министерства культуры и внешних связей Оренбургской области и НПП «РОНА», а также проведенных инженерно-технологических исследований конструкции и росписей здания были получены уникальные сведения об этапах строительства храма, примененных методах и материалах. Данная информация позволила создать научно-обоснованный проект реставрации храма. Профессиональная и добросовестная реализация проекта позволит сохранить уникальный памятник истории и культуры России, объект материального наследия семьи Державиных.

**Литература**

*Колычев С.В.* Г.Р.Державин и его наследие в Оренбургском крае / С.В.Колычев // Г.Р.Державин и диалектика культур. Материалы Международной научной конференции. – Казань; Казанский государственный университет, 2010. – С.120-127

*Солдатова Л.М.* О храме во имя образа Смоленской Богоматери в селе Державино Оренбургской (впоследствии Самарской) губернии / Л.М.Солдатова // Краеведческие записки. – Вып. XII. – Самара. 2005. – С.175-192

## Актуальность переводов произведений Г.Р.Державина
## (Его гений должен звучать и на татарском языке…)

**Л.Р.Миннуллина, А.И.Гаязова**

МБОУ “Школа №144 с углубленным изучением отдельных предметов ”

(Казань)

*Ключевые слова: литературное наследие Г.Р.Державина, переводческая деятельность, популяризация литературы, татарская литературная культура*

Эта статья затрагивает проблемы изучения и возвращения былой славы великого поэта – нашего соотечественника Г.Р.Державина. Начало XXI века – время больших перемен. Ведется активная работа по популяризации творчества великого поэта.

Очевидно, сделан заметный шаг. Проблемы все же остаются. В этой статье прослеживается история переводческой деятельности отдельных представителей литературы.

Известно, что Г. Р. Державина преводили на многие европейские языки: древнегреческий, французский, английский, немецкий, польский и многие другие языки. Встречаются пробы переводов на татарский язык. Они печатались, в основном, на страницах татарских газет и журналов. Но они не имеют серьезного характера. Несомненно, переводить великого мыслителя, представителя классицизма XVIII века сложно и ответсвенно. Отрадно, что успешным представителем этой деятельности следует назвать народного поэта Татарстана Р.М.Хариса. На сегодняшний день в шестом томе его избранных сочинений нашли свое достойное место семь стихотворений Г.Р.Державина в переводе на татарский язык. Сам автор считает, что этот «блаженственный труд» стал для него своеобразным испытанием на поэтическое мастерство и «сам обогатился духовно».

Татарские переводы произведений Г.Р.Державина вносят существенный вклад в развитие русско-татарских литературных связей.

Хотелось бы выразить надежду, что татарские поэты будут активнее переводить, а диалог нашего великого земляка с современной литературой и культурой будет продолжаться.

* * *

Рус классик әдәбиятында Г.Р.Державин иҗаты күренекле урын алып тора. Шул чорның бөек тәнкыйтьчеләре, әдипләре аңа зур бәя биргәннәр. Шагыйрьнең таланты бүгенге көн укучысын да таң калдыра.

Бу исем татар дөньясында, татар культура тарихында да аерым урын били, чөнки ул – безнең ватандашыбыз, якташыбыз. Нәсел тамырларының татар булуын ул бик яхшы белгән, яшермәгән, ә, киресенчә, бу турыда горурланып сөйләгән, язган. Шагыйрь үз туган җиренең патриоты булган дип әйтергә мөмкин. 20 ел Казанда яшәгән, читкә киткәч тә кайтып йөргән. Туган авылын, якыннарын күреп килергә тырышкан.

Казанга, туган җиренә багышлап күп шигырьләр язган.

XVIII йөздә яшәгән шагыйрь Габдессаләм белән иҗади дуслыкта булуы билгеле, кайбер әсәрләрен русчага да тәрҗемә иткән.

Соңгы елларда шагыйрь шәхесенә, аның иҗат мирасына йөз белән борылу күзәтелә. Аңа багышланган фәнни конференцияләр, шигырь бәйрәмнәре, һәйкәл, музей ачу, аның исемендәге премия булдыру һ.б. кирәкле, файдалы эшләр башкарала. Яңа гасыр башы шагыйрь мирасын барлауда күренекле урын алып тора.

Татарстанда бөек шагыйрьнең иҗатын популярлаштыру буенча да актив эш җәелеп китте. Аның әдәби мирасын барлауга галимнәр, мәдәният эшлекләре, шагыйрьләр, тәрҗемәчеләр үз өлешен кертергә тырыша. Нәтиҗәдә, XVIII гасыр

шагыйре һәм хәзерге заман арасында иҗади тыгыз диалог барлыкка килә. Бүгенге көн укучысы өчен аның иҗатын өйрәнү, белү гаять актуаль күренеш.

Татар әдәбияты һәм тәнкыйте тарихына күз салсак, Г.Р.Державин иҗатына зур игътибар бирелгән дип әйтергә нигез юк. Татар публицистикасында шагыйрь турында язып чыгучы беренче мәкалә авторы – Ф.Кәрими. «Шура» журналының 1908 нче ел беренче санында автор татар укучысын Г.Р. Державин шигырьләре белән таныштыру нияте барлыгын яза. Ләкин бу эш тормышка ашмаган дип әйтә алабыз, чөнки тәрҗемәләр әлегә кадәр табылмаган.

Совет чорында шагыйрь шәхесенә игътибар бөтенләй кими, хәтта аның һәйкәле дә җимерелеп юкка чыга.

Шагыйрь иҗатын татар укучысына җиткерү проблемасы соңгы елларда бик актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. Шигырьләрне татар теленә тәрҗемә итү тәҗрибәсе, нигездә, вакытлы матбугат битләрендә урын ала башлады. Мәсьәлән, «Казан утлары», «Казан» журналларында «Арфа» шигыренең аерым өзекләре татар телендә дөнья күрде. Ләкин алар төгәлләнмәгән, аерым строфалар гына чагылыш тапкан. Тәрҗемә проблемасын күтәреп чыгучы һәм шагыйрь тормышына, иҗатына яңача якын килүче берничә галимгә тукталып китү кирәк.

КФУ профессоры Х.Й.Миңнегуловның Г.Р.Державин турында саллы мәкаләсе һәм шигырь бәйрәмнәрендәге чыгышлары зур әһәмияткә ия. Бу хезмәттә галим шагыйрьне бөтенләй икенче яктан ача һәм әлегә кадәр билгеле булмаган кызыклы фактлар китерә. Ике гасыр арасында аңа карата булган карашларны системага сала, тулыландыра һәм баета. «Державин  иҗаты – үзе бер дөнья. Аның иҗатын татар культурасы, әдәбияты белән бәйләп өйрәнү беренче адымнарын гына ясый», – дип искәртә галим. Димәк, алда яңа эзләнүләр көтә.

Шагыйрь иҗатын пропагандалаучы һәм Державин укуларын оештыручы, күп публикацияләр авторы Ә.Ф.Галимуллина үзенең бер мәкаләсендә шагыйрь иҗатын татар теленә тәрҗемә итү мәсьәләләрен хронологик яктан яктырта. «Шунысы куанычлы: шагыйрьнең 260 еллык юбилее уңаеннан  «Мәдәни җомга» газетасында Р.Харис тәрҗемәсендә дүрт шигырь басылып чыкты, – дип яза автор. – Тәрҗемә ителгән шигырьләр, төрле темаларны яктыртса да, яңгырашы белән бик актуаль. Классик шагыйрь ике гасыр элек әйткән фикерләр, шул чор фәлсәфәсе бик дөрес сакланыш тапкан. Билгеле, автор сүзгә сүз тәрҗемә белән мавыкмый, ә эчтәлекне дөрес итеп интонация саклап, шул пафос белән бирергә омтыла. Ул оригиналга бик сакчыл мөнәсәбәттә тора. Автор үзенчәлеген шул заман сулышын дөрес бирүне максат итеп куя. Тәрҗемә мәсьәләсенә аның үз карашы бар».

Р.Харис эшчәнлегенә аерым тукталып үтү кирәк.

Р.Харис – Татарстанның халык шагыйре. Күп премияләр лауреаты, күренекле җәмагать эшлеклесе, 40 якын шигырь һәм поэмалар китапларының авторы. Әдәбият

дөньясында ул яхшы тәрҗемәче буларак та билгеле. Беренчеләрдән булып якташыбыз Г.Р. Державин шигырьләрен тәрҗемә итүче буларак ул зур хөрмәткә лаек. Р. Харис шагыйрь иҗатына зур бәя бирә. Аның сүзләренә караганда, Г. Р. Державин шигырьләре белән ул студент чакта ук таныш булган, аның иҗатының бөеклегенә сокланган. Тәрҗемә итү хыялы белән шактый еллар үткән. Тик 2003 нче елда юбилей мөнәсәбәтләре белән рухланып «Аллаһ» шигырен бер сулышта тәрҗемә итә алган. Бу турыда шагыйрь болай дип яза: «Минем татар телендә ишетәсем килгән, башка телләрдә иҗат ителгән шигырьләрем күп... Шигырь тәрҗемә итү – авыр, ләкин ләззәтле иҗат. Автор җаны никадәрле катлаулы булмасын, аны аңлау – мөмкин эш».

Р.Харисның 7 томлык сайланма әсрләренең 6 нчы томында Г.Р.Державинның 7 шигыре татар телендә лаеклы урын алып тора.

Бу эш дәвамлы булыр дип ышынасы килә. «Сөембикә турында шигырьләр» һ.б. тарихи әсәрләр үз тәрҗемәчесен көтә.

Шагыйрь: «Мин кайчан булсам да, туган ягыма бөтенләйгә кайту уе белән яшим», – дип әйтә торган булган. Ул, чынлап та, яңа көчле шигьри дулкын булып туган ягына кайтты һәм халык күңелендә мәңгелек урын алды. Аның иҗаты белән кызыксыну көннән-көн үсә.

«В могиле буду я, но буду говорить», – дип язган сүзләр бүген дөреслеккә туры килә.

А.С.Пушкин үзенең остазы турында: «Его гений думал по-татарски», – дип әйткән.Шуңа өстәп: «Аның даһилыгы татарча да сөйләсен, татарча да яңгырасын иде», – дип әйтәсе килә.

Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, түбәндәге нәтиҗәләр ясарга мөмкин.

- Г.Р.Державин, бөек шәхес һәм шагыйрь буларак, зур хөрмәткә лаек.
- Шагыйрь әсәрләрен оригиналда гына түгел, ә ул белгән , хөрмәт иткән, татар телендә дә уку мөмкинлекләрен киң җәелдерү зарур.
- Бөек әдип татар укучысына да күңел кылларын тибрәтерлек, күңел түрләрен яктыртырлык булып барып җитәргә тиеш.
- Тәрҗемә эшенә җитди игътибар биреп, лаеклыларны Г.Р.Державин исемендәге премиягә дә тәкъдим итәргә иде.

**Әдәбият**

*Галимуллина А.Ф.* Монография “Дом и душа: размышления о творчестве казанских поэтов” / А.Ф.Галимуллина. – Казань: Школа, 2008.

*Державин Г.Р.* Сочинения / Г.Р.Державин. – М.: Правда, 1985.

*Державин Г.Р.* Водопад / Г.Р.Державин. – М.: Дет.лит., 1960.

*Миңнегулов Х.Й.* Фәнни язмалар – 2008: Фәнни мәкаләләр җыентыгы / Х.Й.Миннегулов. – Казан, 2010.

От Камы до Фонтанки. Г.Р.Державин. – СПб., 2012.

Татарская энциклопедия. – Казань: Институт татарской энциклопедии, 2005. – Т.2.

*Харис Р.М.* Сайланма әсәрләр / Р.М.Харис. – Т.6. – Казан, 2006.

## Г.Р.Державин: казанские страницы (биография и документально-художественная литература)

**Ф.Г.Муртазина**
МБУК «Музей Лаишевского края имени Г.Р.Державина»
(Лаишев)

*Ключевые слова: биография Г.Р.Державина, Казанский край, документально-художественная литература о Державине*

В созвездии писателей и поэтов XVIII века имя Гавриила Романовича Державина – одно из самих ярких.

В своем автобиографическом издании «Записки из известных всем происшествиев и подлинных дел, заключающих в себе жизнь Гаврилы Романовича Державина (1743–1812)» он пишет, что родился в Казани, в семье благородных родителей.

Однако, в с.Сокуры живет предание, что первенец в семье Романа Николаевича и Феклы Андреевны родился именно здесь. В октябре 1742 года в Покровской церкви с. Сокуры состоялось венчание 37-летнего Романа Державина – премьер-майора Свияжского пехотного полка и 36-летней Фёклы Гориной, урожденной Козловой.

«При Великом князе Василье Васильевиче Темном, который скончался в 1462 году, выехал служить из Большой Орды мурза имя Багрим и крещен в православную веру. Ему были пожалованы вотчины в Суздале, Владимире, Переславле, Новгороде и в Нижнем Новгороде. Дмитрия Ильина сына Нарбекова–Алексей, Держава от него служит в Казани»[1].

В XVI в. казанцу Василию Львову был пожалован по Ногайской дороге пустошь Бутырская Лаишевская земля в показании в писцовых книгах Семена Волынского (грамота царя Алексея Михайловича, 1675 г.).

Первое упоминание о владении Ивана Державина имеется в записке Вотчинной коллегии от 31.12.1742 года, составленной на основе отказных книг «испорозших зе-

[1] РНБ. Ф.247